| СОВЕТ КУГЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 5 июне** Күгәй авылы **№161**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. 1 нче кушымта нигезендә җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»2023 елның 26 маендагы 118 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә һәм мәгълүмати стендларда.

**Күгәй авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **Ф. Х. Хисаметдинова**

1 нче кушымта
Кугәй авыл җирлеге Советы
2024 елның 5 июне №161
карарына

Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре

1. 2024 елның 1 гыйнварына җирле салымнар суммасының аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче, түбәндәге нигезләр буенча түләтү һәм (яисә) түләтү мөмкин булмаган суммалар өлешендә түбәндәгеләр түләтүгә ышанычсыз дип танылa:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычы булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнелә торган бурыч булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар түбәндәгеләр була:

1) 1 пунктның 1 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда.

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлү белән бәйле рәвештә салым органнарында исәпкә алынганнан соң физик затны төшерү турында белешмәләр;

в) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләр булмау турында салым органы белешмәсе;

2) 1 пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда.

а) оешма, шәхси эшкуар, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик зат исәбе буенча салым органы белешмәсе, бурыч суммасы турында;

б) салым бетерелгән норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында белешмәләр;

3) 1 пунктның 3 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда, - салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч барлыгы турындагы белешмәсе.